| СОВЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 октябрь 2019 ел. Иске-Тәрбит авылы № 24

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Янсурино торак пунктында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыены билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советына туры китереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге карар кабул итте:

1.2019 елның 4 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Янсурино авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 4 октябрендә билгеләргә.

2. 2019 елның 7 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Янсуры авыл җирлеге Иске Тәрбит авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.2019 елның 9 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Янсурин авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Янсуры авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

« ӨЧЕН» КАРШЫ »

5. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Иске Тәрбит авыл жирлеге башлыгы: В.Г.Тимофеев